



# АЙ НУРЫНА ТӨРЕП

Анатолий Пашин – бик үзенчәлекле талантлы рәссам. Ул дөньяны бөтенләй башкача күрә! Эшләрендәге тональлекне сабый бала сулышына тиңләргә мөмкиндер: Казанның меңьеллыгына, А. С. Пушкинга багышланган монотипияләр, «Шәрык чибәре» сериясе, «Инь-Янь», «Фәрештә» картиналарындагы гаҗәеп хатын-кыз образлары, «Клеопатра», «Чыңгызхан», «Петр I», «Екатерина II» портретлары... Әйе, рәссамның иҗаты кинкырлы! Акрил һәм пастель буяулар, кауры каләм, бай төсләр гаммасын бик оста тоемлап, җанына сыйган галәмне башкалар белән бүлешә. Кечкенә генә бер сызык йә нокта, нәни генә бер тап-төс шундук башка кәеф өсти. Сәнгать белгече Розалина Шаһиева Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Анатолий Пашинның «Йосыф-Зөләйха» поэмасы сериясенә ясалган эшләрен менә ничек тасвирлый: «Иллюстрацияләре алтын белән чигелгән татар милли бизәкләрен һәм татар китап бизәү сәнгатенең гүзәл үрнәкләрен хәтерләтә, нәфис зәвыгы белән сокландыра, алтынсу йөгертелгән саргылт-яшел төсләр, сихерләп, әсәрнең эчке психологиясен тулырак ачарга булыша. «Ай йөзле мәхәббәт»тәге Зөләйхасы шәрык гүзәлләренә, Сөембикә ханбикәгә тиң. «Ай нурына төренгән» Йосыф ак атында Мисырның пирамидалар үзәнен кичә... Гарәп чүлләрендәге ком таулары фоны, челтәрләп эшләнгән бизәкләре белән тәмам хозурлап, Мисыр сәнгатенә ишарәли... Йосыф белән Зөләйханың күрешүен сурәтләгән биттә фәрештәләр аларга мәхәббәт нуры җибәрә... Күктә милли орнамент формасындагы әкияти болытлар йөзә... Илаһи динамика, түгәрәк сызыклар, Болгарның чәчәк ату чорын хәтерләткән оҗмах бакчалары... Кол Галинең йөз чалымнары шәйләнә, азан авазлары, шәрык көйләре ишетелгәндәй була...

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Анатолий Пашин үзен һәм үзеннән элгәргеләрне дә узып, шәрык шигъриятенә йөз тоткан хәлдә, илһамланып, чын фәнтәзи-криптограмма – килечәккә хат юллый...»

Чистайда туган егет Казанда театраль декорация бүлегендә, Харьковта дизайн һәм сәнгать академиясендә укый, Калугада – рәссам, Чаллыда рәссам-проектлаучы булып эшли. Рәссамның иҗат биографиясе 1974 елдан, яшьләр һәм республика күргәзмәләрендә үзен танытудан башлана. Шул вакыттан 2010 елга кадәр ул 30 дан артык шәхси күргәзмәсе белән Мәскәү, Казан, Киев, Самара, Чаллы, Чистай, Алабуга, Түбән Кама сәнгать сөючеләре күңелен яулый. Бөтенсоюз, Бөтенроссия, халыкара конкурсларда катнаша. Ул еллап инде Алтайга барып, анда яшәүче халыкның тормышын, мәдәниятен өйрәнә, бездәге төрки халыклар белән уртаклыклар эзли. Алтай һәм Памир рухы бәркелгән пейзажлардан яктылык агыла. Ә туган якның Кама арьягы табигате йә Зөя утравы күренешләре исә күзләрне иркәли. «Иртәнге сыек томан» картинасындагы ак, сары, яшел, зәңгәрсу, алсу-шәмәхә төсләр, Пашин фантазиясе белән өртелеп, утәкүренмәле пәрдә артыннан ачыла.

А. Пашин педагог та әле. Аның шәхси балалар сәнгать студиясе «Сирин» бар! Укучылары Япониядә, Франциядә, Һиндстанда узган халыкара күргәзмәләрдән җиңүчеләр булып кайта.

Ул – кабатланмас шәхес, фәлсәфи рәссам. Пар алма ясап – Адәм белән Һаваны, көймәләр төшереп – ир белән хатынны ача алган. Шундый картинасы да бар: төп персонажлар – Ышаныч, Өмет, Мәхәббәт.

Эльмира ЗАКИРОВА






АНАТОЛИЙ ПАШИН